РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2020 елның 22 гыйнвары г. Буа шәһәре 13 /ИК-п номерлы

2019-2023 елларга Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районында кече һәм урта
эшкуарлыкны үстерү һәм аңа ярдәм итү
муниципаль программасына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 3 өлешенә, «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 2 өлешенә, Буа муниципаль районы Уставына нигезләнеп Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү һәм аңа ярдәм итү буенча «2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү һәм аңа ярдәм күрсәтү буенча муниципаль программаны раслау турында» 2019 елның 6 июнендәге 254/ИК - п номерлы карары белән расланган муниципаль программага түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. I бүлек:

«Программаның максатлары һәм бурычлары»:

8 пунктны «... бизнес, шул исәптән социаль эшкуарлык;» сүзләре белән тулыландырырга;

1.2. II бүлек:

икенче абзацны « ... эшкуарлык, шул исәптән социаль эшкуарлык -…» сүзләре белән тулыландырырга;

1.3. II бүлек:

1 пунктның 2 пунктчасына «...КУЭ, шул исәптән социаль эшкуарлык...» сүзләрен өстәргә;

1.4. IV бүлек:

3 пунктка «..социаль эшкуарлык исәбендә... » сүзләрен өстәргә;

4.3 пунктның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3. Кече эшкуарлык субъектларына, шул исәптән социаль эшкуарлыкка финанс-кредит һәм мөлкәт ярдәме күрсәтү.»;

4.4 пунктның таблица өлешендә. 2 пунктта түбәндәге сүзләр өстәргә: «…КУЭ, шул исәптән социаль эшкуарлык …»;

1.5. V бүлек:

1 абзацны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«КУЭ субъектларын ресурслар белән тәэмин итү түбәндәге формаларда гамәлгә ашырыла:

– КУЭка финанс ярдәме, шул исәптән социаль эшкуарлыкка да;

– кече һәм урта эшкуарлыкка мөлкәти ярдәм күрсәтү, шул исәптән социаль эшкуарлыкка да;

– КУЭка, шул исәптән социаль эшкуарлыкка мәгълүмати ярдәм;

– кече һәм урта эшкуарлыкка, шул исәптән социаль эшкуарлыкка консультация ярдәме;

– КУЭ хезмәткәрләрен әзерләү, яңадан әзерләү һәм квалификацияләрен күтәрү өлкәсендә ярдәм итү.»;

1.6. Программага 3 нче кушымтада «2019-2023 елларга Буа муниципаль районының кече эшкуарлыкны үстерү буенча программа чаралары.»:

3 пунктның исемен үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Кече эшкуарлык субъектларына, шул исәптән социаль эшкуарлыкка финанс-кредит һәм мөлкәт ярдәме күрсәтү.»;

4 пунктның икенче өлешендә уң як кырый бағананы ( столбец) үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү һәм аны тотрыклы үстерү, шул исәптән авыл хуҗалыгында социаль эшкуарлыкны үстерү.»;

2. Әлеге карар рәсми бастырылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча http://buinsk.tatarstan.ru урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә йөклим.

Буа муниципаль районы Башкарма
комитеты җитәкчесе Р.Р. Камартдинов